Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе «Кәрәкәшле төп гомуми белем бирү мәктәбе»

| “Каралды” МБГББУ “Кәрәкәшле ТГББМ” башлангыч сыйныф укытучылары методик берләшмәсе җитәкчесе ________Нәгыймова И.С. Протокол № 1_ “23” август 2023 ел | “Килешенде” МБГББУ “Кәрәкәшле ТГББМ” укыту тәрбия эшләре буенча директор урынбасары ________Әхмәтова Э.Ф. “24” август 2023 ел | “Расланды” МБГББУ “Кәрәкәшле ТГББМ” директоры ________ Закиров М.Ш. Приказ № 71 “24” август 2023 ел_ |
|---|---|---|

# 3 сыйныф өчен

# татар теле буенча

# укыту курсының эш программасы

Укытучы Нәгыймова Илсөяр Сәет кызы

Еллык сәгатьләр саны 102, атнага 3 сәгать

Кәрәкәшле авылы, 2023 ел

**I .Аңлатма язуы**

**1.1 Татар теленнән 3 нче класс өчен эш программасы түбәндәге норматив документларга нигезләнеп төзелде :**

Планлаштырылган контроль дәресләр ______,зачѐт ________, практик эшләр____, тестлар______

КТП түб̈ендеге документларга нигезл̈енеп т̈езелде: -

-Татарстан Республикасы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе “Кәрәкәшле төп гомуми белнм бирү мәктәбе”нең башлангыч гомуми белем бирүнең программасы

-Татарстан Республикасы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе “Кәрәкәшле төп гомуми белем бирү мәктәбе” укыту планы;

Туган (татар) тел фәненнән эш программасын төзүчеләр: Мөгътәсимова З.Н., Әхмәтова Э.Ф., Нәгыймова И.С.,Мөрәсова Г.Р., 2023 ел

Туган (татар) телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен татар теленнән программага нигезләнеп төзелде. И.Х. Мияссарова, Ф.Ш. Гарифуллина, Р.Р.Шәмсетдинова, Ч.М. Харисова, К.М. Фәйзрахманова. Казан:”Мәгариф-вакыт” нәшр. 2015 ел

Уку әсбабы: И.Х. Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова Татар теле. Казан “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты 2021 ел

**II. Укыту предметының гомуми характеристикасы**

**Татар теле дәресенең максаты:**
-укучыларда уңышлы аралашу сәләте булдыру-әйтмә һәм язма сөйләмне үстерү, каракаршы сөйләшү осталыгы, монолог төзү һәм шулай ук гомуми культура күрсәткече булган грамоталы язу күнекмәләре булдыру, укучыларны тел фәненең төп мәгълуматлары белән таныштыру һәм шулар нигезендә аларның тамга символик һәм логик фикерләвен үстерү, татар теленең башка телләр белән берлектә дөньяның фәнни картинасын тудыруда катнашуы,аның милләте саклап калуда, халыкның, шәхеснең үзенчәлеген югалтмауда ышанычлы нигез, җәмгыятнең яшәешенә зарури шарт булуы турында күзаллау барлыкка китерү.

**Бурычлар:**
-балаларның сөйләм осталыгын, фикерләү сәләтен һәм иҗади хыялын үстерү, ана телендә аралашу максатына, бурычларына,шартларына туры килгән тел чаралары сайлый белергә, уй-фикерләрен төгәл белдерергә һәм әңгәмәдәше әйткәнне тәңгәл аңларга күнектерү
-телнең лексикасы,фонетикасы һәм грамматикасы буенча программада күрсәтелгән башлангыч белемнәрне үзләштерүгә ирешү
-укучыларда дөрес уку һәм язу күнекмәләре булдыру, диалогта катнашырга һәм аларны зур, катлаулы булмаган монолог тибында төзеп әйтергә, тасфирлама, хикәяләү, фикер йөртү төрендәге кечкенә текстлар төзергә өйрәтү, уңышлы аралашу сәләте тәрбияләү

Башлангыч сыйныфларда ана телен өйрәнү –балаларга тел белеме буенча системалы мәгълүматләр бирү һәм сөйләм үсешен тәэмин итүдә беренчел этап.Бу чорда ана телен өйрәнү башка фәннәр белән тыгыз бәйләнештә алып барыла.Татар теле

дәресләрендә телнең системасы тирәнтен өйрәнелә,сөйләм культурасы үзләштерелә. Кече яшьтәге балаларның аралашу гамәлендә актуаль булган ситуацияләрдә кирәкле осталык һәм күнекмәләр булдырыла, сөйләм жанрының төрләре (записка,хат,котлау, чакыру язу) үзләштерелә.Орфография һәм пунктуацион кагыйдәләре фонетика,морфология, морфемика һәм синтаксисны өйрәнү кысаларында үзләштерелә.Ана теленең орфография принциплары белән танышу да кертелә.

Дәреслекне төзүче авторлар (И.Мияссарова, К.Фәйзрахманова) тәкъдим итә торган УМК (программа, ике кисәктән торган дәреслек, методик кулланма, мөстәкыйль эш дәфтәре), ана телен укытуның традицион формаларын читкә какмыйча, укучыларда тел берәмлекләренә, заман таләпләреннән чыгып, уңай мөнәсәбәт тәрбияләүгә юнәлтелә.Дәреслекне төзүче авторлар 3 сыйныф укучысының яшь үзенчәлегенә нигезләнеп эшләгәннәр.Дәреслекләрдә “яшәүче” геройлар Әминә белән Әмир укучыларга программа материалын үзләштерергә ярдәм итәләр. Татар теле дәресләрендә укучыларның сүз байлыгын арттыру, даими рәвештә орфоэпик һәм орфографик нормаларны төгәл үтәү максатыннан,”Дөрес әйт”, ”Дөрес яз” сүзлекләре һәм “Аңлатмалы сүзлек” белән эшләүгә нык игътибар ителә.Дәреслекнең беренче кисәгендә укучылар яңа сүзләр белән танышалар,ә икенчесендә әлеге сүзләр белән сүзлекләр ярдәмендә эшләп, аларның дөрес әйтелеше һәм язылышы ныгытыла.”Аңлатмалы сүзлек”тән яңа өйрәнгән сүзнең мәгънәсен ачыклыйлар.Шул сүзләр белән сүзтезмә һәм җөмләләр төзетү, аларны диалог һәм монологлар төзүдә файдалану укучыларның сүз байлыгын арттырачак, бәйләнешле сөйләм оештырырга ярдәм итәчәк.

**III. Предметның укыту планындагы урыны**

Татар теле **“Татар теле” белем бирү өлкәсенә** карый, гуманитар фәннәр циклына керә. **Программа 2023 – 2024 нче уку елына 102 сәгатькә исәпләнеп төзелгән; атнага 3 сәгать вакыт бирелә.**

**IV. Уку предметы эчтәлегенең рухи кыйммәтләре**

Татар теле курсын өйрәнү нәтиҗәсендә укучылар телнең аралашуның төп чарасы һәм милли культураның төп күренеше икәненә төшенә; укучыларда туган телгә карата позитив эмоциональ кыйммәтләр формалаша; туган тел укучылар өчен уку процессының нигезе, фикерләү, күзаллау, интелектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүдә зур таяныч булып тора. Туган телне өйрәнү барышында укучылар үзләренең иҗади сәләтләрен язма һәм сөйләм теле аша тормышка ашыра, телне мөһим мәгълүматны эзләү һәм табу өчен куллана. Укучылар ел дәвамында хатасыз язуның культуралылык билгесе икәнен аңлый, орфография кагыйдәләрен куллана, күчереп язуны, сүзләрдән җөмләләр, җөмләләрдән кечкенә хикәяләр төзи белү күнекмәләрен камилләштерә.

**V.Укыту предметын үзләштерүнең шәхси, метапредметлы һәм предметлы нәтиҗәләре**

**Бирелгән программа буенча укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр**

**Укучылар белергә тиеш :**

- кушма сүз, парлы сүз; тамыр һәм ясалма сүзләр;
- өйрәнелгән сүз төркемнәрен һәм аларның билгеләрен : исем, фигыль, сыйфат, зат алмашлыклары, алмашлык, кисәкчә, бәйлек;

**Укучылар башкара алырга тиеш :**

- сүзләрдәге орфограммаларны табу һәм аларның язылышын кагыйдәләргә нигезләнеп аңлату;
- үтелгән орфограммалар кергән 55-60 сүзле текстны хатасыз һәм каллиграфик итеп күчереп һәм ишетеп, тыныш билгеләрен дөрес куеп язу;
- сүзләрне төзелешләре ягыннан тикшерү;
- сүзнең тамырын һәм кушымчаларын табу;
- кушымчаларның төрен билгеләү;
- кушма һәм парлы сүзләрне билгеләү;

- сүзләрне сүз төркеме ягыннан тикшерү : исемнең сан, килеш кушымчасын билгеләү;
- сыйфатның дәрәҗәләрен аеру;
- фигыльнең зат – сан, заманын күрсәтү;
- текстның темасын, төп фикерен билгеләү;
- темага һәм төп фикергә таянып, текстка исем кую;
- текстның планын төзү;
- хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү характерындагы текстларны аера белү һәм сөйләмдә куллану;
- культуралы мөгамәлә таләпләренә туры китереп, үтенеч, гафу үтенү, рәхмәт әйтү, баш тарту, чакыру, котлау – тәбрикләү сүзләрен сөйләмдә куллану;
- тасвирлау һәм фикер һөртү элементлары кергән 70-75 сүзле хикәяне изложение итеп язу;
- хикәяләү характерындагы сочинение язу.
- кеше исемнәрен, фамилияләрен, шәһәр, авыл ,елга, исемнәрен, хайван кушаматларын баш хәреф белән язу.
- программада булган сүзләрне дөрес язу һәм юлдан –юлга күчерү
- сүзгә фонетик анализ ясау, иҗекләргә бүлү,авазларны сүздәге тәртиптә ачык, дөрес әйтеп атап чыгу,
- үзең язганны бирелгән үрнәк белән чагыштыру
- сүзләргә дөрес сорау кую һәм шуның нигезендә предметны ,предметның эшен,хәрәкәтен, билгесен, өстәмә предметны, ярдәмче сүзләрне таба белү
- җөмләнең баш кисәкләрен таба белү; уку, уеннар, көндәлек тормыш, табигать турындагы темаларга 7-8 җөмләдән торган бәйләнешле текст төзеп сөйләү һәм язу
- сүзләрнең әйтелешен, кулланышын, язылышын истә калдыру:

*авыр,акбур,акош,алъяпкыч, ап-ак, аръяк, ашъяулык, аю,әдип,әти-әни, әһәмият, бала-чага, әһәмият, берәз, бияләй, булдыклы, буяу, вак, Ватан,гади, гаилә,гайртле, давыл, данә, дөя, егрле, елан, җәелә, җәза, җәнлек, җиз, җиһаз, илле, йокы, кадерле, карабүрек, кәгазь, кәккүк, кием, кошчык, котлы, көе, көнбагыш, коньяк,көянтә, куәтле, күбрәк, күңелле, мәгънә, мәкаль, мәсьәлә, мәңге, милләт, морҗа, нәүрәз, ният, охшый, ошый, өрәңге,өянке, пөхтә, рөхсәт, русча, сава, салават, саңгырау, сәгать, сәламәт, сәхнә, сәяхәт, соңгы, сөенеч, сөяк, табигать,ташбака, таң, тәңкә, тиеш, тимераяк, тозсыз, төяк, төен, төнбоек, төньк, тыңлау, уйсу, үрмәкүч, чаңгы, чәучәк, чәүкә, чуар, чынаяк, шигырь, элекке, эре, юаныч, юаш, юкә, юлчы, юнәлеш, юына, ябалак, явыз, якты, ямьле, ять, ярдәм, ятьмә,яхшы, яшь.*

## Шәхси, метапредметлы һәм предметлы нәтиҗәләр

**Шәхси нәтиҗәләр:**

- туган илгә карата шәхси караш булдыру;
- чын кеше сыйфатлары булдыру;
- мөстәкыйльлелек һөм җаваплылык үстерү;
- этик хисләр, мөлаемлылык үстерү;
- рухи-әхлакый идеалларына китерү.
- олылар белән хезмәттәшлек;
- аралашу культурасы күнекмәләре .

**Метапредметлы нәтиҗәләр:**

- аң -белем үстерү;
- проблемаларны мөстәкыйль рәвештә таба алу;
- эзләнү юлларын һөм нәтиҗәләрен ачыклау;

- логик фикерләү:чагыштыру, синтез, анализ ясый белү;
- конфликтлы ситуацияләрдән чыгу юлын табу;
- укучыларның образлы, логик фикерләвен үстерү;

**Предметлы нәтиҗәләр:**

- Россиядә күп милләт халыкларының төшенчәсен бирү;
- татар теленең төп төшенчәләр буенча башлангыч белем ( фонетик, лексик, грамматик);
- татарча югары сөйләм культурасы формалаштыру;
- туган телнең орфоэпик, лексик, грамматик төшенчәләре;
- сүз турында башлангыч төшенчәләр формалаштыру;
- уку, язу гамәлләре формалаштыру;
- сүзгә фонетик анализ ясый белү.

**Универсаль уку гамәлләре формалаштыру:**

***Танып белү универсаль уку гамәлләре:***

- дәреслектә ориентлаша белү;
- шартлы билгеләрнең телен белү;
- рәсем һәм схемалар нигезендә биремнәр үтәү;
- төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;
- материаль объектлар кулланып биремнәр үтәү;
- дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәрендәге мәгълүматлар белән эшли белү;

***Регулятив универсаль уку гамәлләре:***

-кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;
- гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау;
- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;
- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.

***Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре:***

- дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үз уңышларын/уңышсызлыкларың турында фикер йөртү;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү;
- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;
- мәгънә барлыкка китерү («Минем өчен моның нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорау кую)

***Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:***

- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- күршең белән хезмәттәшлек итү;
- үз фикереңне һәм позицияңне формалаштыру;
- уртак эшчәнлеккә һәм гомуми чишелешкә килү;
- партнёрның нәрсәне белүен һәм күрүен, нәрсәне белмәвен һәм күрмәвен исәпкә алып, аңлаешлы сөйләм төзергә, сораулар бирү;
- партнёрның эш-гамәлләрен контрольгә алу;
- сөйләмнең диалог формасын үзләштерү.

## VI. Укыту предметының эчтәлеге

| № | Эчтәлек | Сәг. саны |
|---|---|---|
| 1 | **Орфограмма.1-2 сыйныфта үткәннәрне кабатлау.** | 11 сәг. |
| 2 | **Сүз. Телнең сүзлек байлыгы.-** | 8 сәг. |
| 3 | **Сүз төзелеше.Сүз ясалышы.** | 8 сәг. |
| 4 | **Сүз төркемнәре** | |
| | Исем | 13 сәг. |
| | Фигыль | 18 сәг. |

| | | |
|---|---|---|
| | Сыйфат | 9 сәг. |
| | Алмашлык | 5 сәг. |
| | Кисәкчәләр | 4 сәг. |
| | Бәйлекләр | 2 сәг. |
| **5** | **Җөмлә** | 9 сәг. |
| **6** | **Сүзтезмә.** | 1 сәг. |
| **7** | **Текст.Бәйләнешле сөйләм** | 10 сәг. |
| **8** | **Ел буена үткәннәрне кабатлау** | 4 сәг. |
| | **Барысы** | 102 сәг. |

## VII . Программа эчтәлеге (102 сәг.)

### Орфограмма. 1-2 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау (11 сәг.)

Калын һәм нечкә сузыклар. Яңгырау һәм саңгырау тартыклар. Тавышсыз хәрефләр. Парлы һәм парсыз яңгырау һәм саңгырау тартыклар.Калын һәм нечкә сузык авазлар. Е,я,ю хәрефләренең сүз башында һәм сузык авазлардан соң ике аваз белдергән очракларын танып белү һәм шул хәрефләр кергән сүзләрне дөрес уку, күчереп язу. Ъ, ь хәрефләренең аваз белдермәгәнлеген истә тоту, шул хәрефләр кергән сүзләрне дөрес уку. Сүзгә фонетик анализ ясау.

### Сүз. Телнең сүзлек байлыгы (8 сәг.)

Сүз.Сүзнең лексик мәгънәсе. Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр. Синонимнар. Антонимнар. Омонимнар. Аларның сөйләмдәге роле. Сүзнең күп мәгънәлелеген һәм күчерелмә мәгънәсен (фразеологик әйтелмәләр) куллану. Татар теленең сүз байлыгы. Дәреслекләрдәге сүзлекчәләрдән, сүзлекләрдән сүзнең аңлатмасын табып алу.
Сүзтезмә белән белдерелгән лексик берәмлекләр: сөт өсте, җир җиләге һ.б.

### Сүз төзелеше. Сүз ясалышы (8 сәг.)

Морфология һәм аның состав өлешләре. Бер тамырдан берничә сүз ясалу, кушымчалар, аларның яңа сүз ясаудагы роле.

Тамырдаш сүзләр. Сүзләрнең ясалыш буенча төрләре (ясалма, кушма, парлы сүзләр).

### Сүз төркемнәре

### Исем (13 сәг.)

Сүз төркемнәре төшенчәсе. Исем. Исемнең предметлык төшенчәсен белдерүе, аның җөмләдә ия булып килүе. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Исемнәрне тематик төркемләү.

Исемнең берлек һәм күплек санда килүе. Күплек кушымчалары, аларның дөрес әйтелеше һәм ясалышы.

Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Татар телендә килешләр һәм аларның сораулары. Сузык авазларга һәм яңгырау тартыкларга беткән исемнәрнең килешләр белән төрләнүе.

### Фигыль (18 сәг.)

Фигыль сүз төркеменең мәгънәсе һәм сораулары. Фигыльнең барлык һәм юклык төрләре. Фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Хикәя фигыльөч заманы: үткән заман, киләчәк заман, хәзерге заман.Фигыльнең заман формаларын дөрес ясау. Фигыльнең күп мәгънәлелеге.

### Сыйфат (9 сәг.)

Сыйфатларның семантик төркемнәре. Сыйфат дәрәҗәләре (гади, чагыштыру, артыклык, кимлек  дәрәҗәләре).

**Алмашлык (5 сәг.)**

Алмашлыкның мәгънә үзенчәлегенә –зат һәм предметны атамыйча, исемен генә алыштырып килүенә күзәтүләр. Зат алмашлыклары, килеш белән төрләнүе. Аларның җөмләләрне бер-берсенә бәйләүдәге роле.

**Кисәкчәләр (4 сәг.)**

*Да-дә, та-тә* кисәкчәләрен  *-да/-дә, -та/-тә* кушымчаларыннан аеру. Кисәкчәләрне дөрес язу.

**Бәйлекләр (2 сәг.)**

Төрле килешләрдә исемнәрне  һәм зат алмашлыкларын *белән, саен, шикелле, өчен, аркылы, таба, хәтле, каршы, кадәр, чаклы, бирле, соң, башка* бәйлекләре белән куллану.

**Җөмлә (9 сәг.)**

Хикәя, сорау, өндәү (боеру), тойгылы җөмләләр. Аларны текстта аера белү.

Җөмләнең әйтелү максаты буенча төрләренә карап, җөмлә ахырына тыныш билгесе кую. Җөмләнең баш кисәкләре . Язма сөйләмдә ия һәм хәбәрнең урыннары.

Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. Җыйнак җөмләне, тиешле сүзләр өстәп, җәенкеләндерә белү, җәенке җөмлә эченнән баш кисәкләрне генә аерып чыгару.

**Сүзтезмә (1 сәг.)**

Сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне аера белү, мәгънәләре, сораулар ярдәмендә җөмләдә сүзләр бәйләнешен ачыклау, сүзтезмәдәге ияртүче һәм иярүче сүзләрне билгеләү.

**Бәйләнешле сөйләм (10 сәг.)**

Текстның темасын һәм төп фикере. Исемсез текстларның темасын билгеләү һәм исем кую. Төп фикерне темадан аера белү һәм аларны төгәлбилгеләү.

Текстның типлары: хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү. Аларның төп үзенчәлекләре.

Әзер яки күмәк төзелгән план буенча хикәяләү тибындагы текстны изложение итеп язу. Сюжетлы рәсемнәр һәм картиналар буенча укучыларның тормыш тәҗрибәсенә, күзәтүләренә, укыганнарына бәйле темаларга сочинениеләр язу. Телдән эш характерындагы текстлар төзү.

Сөйләм этикасы. Телдән һәм язмача чакыру, тәбрикләү.

**Ел буена үткәннәрне кабатлау (4сәг.)**

“Сүзнең төп (лексик) мәгънәсе” темасы. Сүз төзелеше. Сүз ясалышы. Сүз төркеме. Исем. Исемнәрнең килеш белән төрләнүе. Сүз төркеме.
Фигыль. Фигыльнең заман белән төрләнеше. Сүз төркеме.Сыйфат. Бәйләнешле сөйләм.
“Җәй”. Сүз төркеме.Алмашлык. Кисәкчәләр. Бәйлекләр. Җөмлә. Сүзтезмә. Бәйләнешле сөйләм.

## VIII.  Уку материалын календарь –тематик планлаштыру.

| № | Дәрестемасы | Дәрес саны | дата | | искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | план | факт | |
| 1. | **Орфограмма. 1-2 сыйныфларда үткәннәрне кабатлау. (11 сәгать)**<br>1-2 нче сыйныфларда үткәннәрне кабатлау. Орфография сүзенең мәгъ-нәсен ачыклау.”Аңлатмалы сүзлек” белән эш. | 1 | 01.09 | | |
| 2. | *Бәйләнешле сөйләм* .Рәсем буенча хикәя төзү”Җәй көне”. | 1 | 06.09 | | |
| 3. | Авазлар һәм хәрефләр. | 1 | 07.09 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 4. | **Сузык һәм тартык авазлар.** | 1 | 08.09 | | |
| 5. | Иҗек. Иҗек төзелеше. Сүзләрне юлдан юлга күчерү. Ъ, Ь хәрефләре.Аларның дөрес язылышы | 1 | 13.09 | | |
| 6. | Я, ю, е хәрефләре. Әйтелеш һәм язылыш ,аваз кушылмалары.Алфавит тәртибе. | 1 | 14.09 | | |
| 7. | **Кереш контроль диктант.** | 1 | 21.09 | | |
| 8. | Сүз төзелеше.Тамыр һәм кушымча. Тамырдаш сүзләр. | 1 | 15.09 | | |
| 9. | Сүз төркемнәре. Җөмлә.Иҗади биремле күнегүләр. | 1 | 20.09 | | |
| 10. | **Хаталар өстендә эш.** | 1 | 22.09 | | |
| 11. | 1-2 сыйныфларда үткәннәрне кабатлау. | 1 | 27.09 | | |
| 12. | **Сүз. Телнең сүзлек байлыгы ( сәг.8)**<br>**С**үзнең төп (лексик) мәгънәсе.Аңлатмалы сүзлекләр белән эш , лексик мәгънәгә туры килгән сүзләр табу. | 1 | 28.09 | | |
| 13. | Алынма сүзләр, аларны куллану өлкәсе. | 1 | 29.09 | | |
| 14. | Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр. | 1 | 04.10 | | |
| 15. | Әйтелеше бертөрле, мәгънәләре башка сүзләр – омонимнар | 1 | 05.10 | | |
| 16. | Охшаш мәгънәле сүзләр – синонимнар. | 1 | 06.10 | | |
| 17 | Искәртмәле диктант | | 11.10 | | |
| 18. | Хаталар өстендә эш. Капма-каршы мәгънәле сүзләр – антонимнар. | 1 | 12.10 | | |
| 19. | Тотрыклы сүзтезмәләр,фразеологик әйтелмәләр белән танышу. | 1 | 13.10 | | |
| 20. | **Сүз төзелеше. Сүз ясалышы (8 сәгать)**<br>Тамыр һәм кушымча. | 1 | 18.10 | | |
| 21. | Сүз ясагыч кушымчалар.Алар ярдәмендә сүзләр ясалуын карау,ясау, ясалма сүзләр. | 1 | 19.10 | | |
| 22. | Төрләндергеч кушымчалар, алар ярдәмендә сүзләрнең үзгәрүен күзәтү. | 1 | 20.10 | | |
| 23.<br>24 | Кушма сүзләр , аларның ясалышы һәм дөрес язылышы.Сайланма диктант. | 2 | 25.10<br>26.10 | | |
| 25. | Парлы сүзләр,аларның ясалышы һәм дөрес язылышы. | 1 | 27.10 | | |
| 26. | **“Сүз төзелеше. Сүз ясалышы” Грамматик биремле контроль диктант.”Кыш бабай бизәкләре” №2.** | 1 | 08.11 | | |
| 27. | Хаталар өстендә эш. “Сүз төзелеше. Сүз ясалышы” темасын кабатлау. | 1 | 09.11 | | |
| 28. | **Исем (13 сәг.)**<br>Сүз төркемнәре. Сүзләрнең төркемнәргә бүленеше | 1 | 10.11 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 29. | Исем. Мәгънәсе, сораулары, җөмләдәге роле. | 1 | 15.11 | | |
| 30. | Ялгызлык исемнәр.Ялгызлык төшенчәсе, төркемнәре,язылышы. | 1 | 16.11 | | |
| 31. | Уртаклык исемнәр.Уртаклык төшенчәсе, язылышы.Сүзлек диктанты. | 1 | 17.11 | | |
| 32. | Берлек һәм күплек сандагы исемнәр.Берлек һәм күплек сан формалары,берлектән – күплек,күплектән-берлек ясау. | 1 | 22.11 | | |
| 33. | **Изложение № 1 ”Песи баласы”.** | 1 | 23.11 | | |
| 34 | Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Баш килеш | 1 | 24.11 | | |
| 35. | Иялек килеше. Иялек килеш төшенчәсе, сораулары, кушымчалары; калын һәм нечкә төрләнеш. | 1 | 29.11 | | |
| 36. | Юнәлеш килеше. Юнәлеш килеш төшенчәсе, сораулары, кушымчалары; калын һәм нечкә төрләнеш; саңгырау һәм яңгырау тартыкларга, сузык авзга беткән исемгә кушымча ялгау. | 1 | 30.11 | | |
| 37. | Төшем килеше. Төшем килеш төшенчәсе, сораулары, кушымчалары; калын һәм нечкә төрләнеш; саңгырау һәм яңгырау тартыкларга, сузык авазга беткән исемгә кушымча ялгау. | 1 | 01.12 | | |
| 38. | Чыгыш килеше. Чыгыш килеш төшемчәсе, сораулары, кушымчалары; калын һәм нечкә төрләнеш; борын авазларына беткән исемнәргә чыгыш килеш кушымчасы ялгау. | 1 | 06.12 | | |
| 39. | Урын-вакыт килеше. Урын-вакыт килеш төшемчәсе, сораулары, кушымчалары; калын һәм нечкә төрләнеш. | 1 | 07.12 | | |
| 40. | “Исемнәрнең килеш белән төрләнеше” темасын ныгыту. | 1 | 08.12 | | |
| 41. | **Фигыль ( 18 сәгать)**<br>Фигыль сүз төркеменең мәгънәсе һәм сораулары, җөмләдәге роле. | 1 | 13.12 | | |
| 42 | Фигыльнең барлык һәм юклык төрләре. | 1 | 14.12 | | |
| 43. | Фигыльләрнең зат-сан белән төрләнеше. Ия белән фигыльнең ярашуы. | 1 | 15.12 | | |
| 44. | **“Фигыльләрнең зат-сан белән төрләнеше” Грамматик биремле контроль диктант.”Карлар ява” №3. 2 нче чирекне йомгаклау.** | 1 | 20.12 | | |
| 45. | Хаталар өстендә эш. Фигыль заманнары. Хикәя фигыль. | 1 | 21.12 | | |
| 46. | Хикәя фигыльнең заман белән төрләнеше. | 1 | 22.12 | | |
| 47. | Хәзерге заман хикәя фигыльнең белдерелеше, сораулары, ясалышы, юклык төр кушымчалары, сөйләмдә аларны аера белү. | 1 | 27.12 | | |
| 48 | Үткән заман хикәя фигыльнең белдерелеше, сораулары, сөйләмдә аларны аера белү. | 1 | 28.12 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 49 | Үткән заман хикәя фигыльнең төрләре, барлык һәм юклык формалары. | 1 | 29.12 | | |
| 50. | Үткән заман хикәя фигыль | 1 | 10.01 | | |
| 51. | Киләчәк заман хикәя фигыльнең белдерелеше, сораулары, кушымчалары; сөйләмдә аларны аера белү. | 1 | 11.01 | | |
| 52 | Киләчәк заман хикәя фигыльнең беренче төре. | 1 | 12.01 | | |
| 53-54 | .Киләчәк заман хикәя фигыльнең икенче төре. | 2 | 17.01<br>18.01 | | |
| 55. | Киләчәк заман хикәя фигыль.Аңлатмалы диктант. | 1 | 19.01 | | |
| 56 | Фигыльләрнең күп мәгънәлелеге | 1 | 24.01 | | |
| 57 | Изложение язу. | | 25.01 | | |
| 58. | Хаталар өстендә эш. “Фигыль” темасын ныгыту. Тест биремнәре. | 1 | 26.01 | | |
| 59. | **Сыйфат (9 сәгать)**<br>Сыйфатлар нәрсәне белдерәләр, сөйләмдәге әһәмияте. | 1 | 31.01 | | |
| 60. | Сүзтезмәләрдәге сыйфатлар.Сөйләмдәге әһәмияте һәм кулланышы. | 1 | 01.02 | | |
| 61. | Сыйфат дәрәҗәләре. Гади дәрәҗәдәге сыйфат, ясалышы һәм дөрес язылышы. | 1 | 02.02 | | |
| 62. | Чагыштыру дәрәҗәсендәге сыйфатлар,ясалышы һәм дөрес язылышы. | 1 | 07.02 | | |
| 63. | Артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатлар, ясалышы һәм дөрес язылышы. | 1 | 08.02 | | |
| 64. | Кимлек дәрәҗәсендәге сыйфатлар, ясалышы һәм дөрес язылышы. | 1 | 09.02 | | |
| 65. | “Сыйфат дәрәҗәләре” темасын ныгыту.Иҗади биремле күнегү. | 1 | 14.02 | | |
| 66. | “Сыйфат дәрәҗәләре” темасы буенча искәртмәле диктант. | 1 | 15.02 | | |
| 67. | Хаталар өстендә эш. “Сыйфат” темасын кабатлау.Тест биремнәре. | 1 | 16.02 | | |
| 68. | **Алмашлык (5 сәгать)**<br>Алмашлык,дөрес әйтелеш һәм язылыш. | 1 | 21.02 | | |
| 69. | Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнәнеше.Аларның җөмләләрне бер-берсенә бәйләүдәге роле. | 1 | 22.02<br>28.02 | | |
| 70. | Берлек һәм күплек сандагы зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше. | 1 | | | |
| 71. | **Контроль күчереп язу.** | 1 | 29.02 | | |
| 72. | Хаталар өстендә эш. “Алмашлык” темасын ныгыту.Тест биреме. | 1 | 01.03 | | |
| 73 | **Кисәкчәләр (4 сәгать)**<br>Кисәкчәләр.Да,дә,та,тә.Ярдәмче сүзләрне сөйләмдә куллану,тикшерү,кисәкчәләрне билгеләү. | 1 | 06.03 | | |
| 74 | Генә,гына,бит кисәкчәләре. Ярдәмче сүзләрне сөйләмдә куллану,тикшерү,кисәкчәләрне билгеләү. | | 07.03 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 75. | Ич,ук-үк,һич кисәкчәләре. Ярдәмче сүзләрне сөйләмдә куллану,тикшерү,кисәкчәләрне билгеләү. | 1 | 13.03 | | |
| 76 | Рәсем буенча хикәя язу.”Өмәдә” | 1 | 14.03 | | |
| 77. | **Бәйлекләр ( 2 сәгать)**<br>Бәйлекләр.Бәйлекләрнең җөмләдәге роле. | 1 | 15.03 | | |
| 78. | “Бәйлекләр” **Грамматик биремле контроль диктант. №4. 3 нче чирекне йомгаклау.** | 1 | 20.03 | | |
| 79. | **Җөмлә (9 сәгать)**<br>Хаталар өстендә эш.Җөмлә төшенчәсе; укылыш,тавыш куелышын тыныш билгесенә карап билгеләү. | 1 | 21.03 | | |
| 80. | Хикәя җөмлә.Әйтелеш максаты буенча төрләре-хикәя җөмлә, тыныш билгесе, сөйләм төзү. | 1 | 22.03 | | |
| 81 | Сорау җөмлә, тыныш билгесе, диалогта куллану. | 1 | 03.04 | | |
| 82. | Өндәү (боеру) җөмлә белдерелеше, тыныш билгесе, җөмләләр төзу.Тойгылы җөмлә. Көчле тойгы белән җөмлә төзү | 1 | 04.04 | | |
| 83 | Җөмлә кисәкләре. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре: ия һәм хәбәр, аларның белдерелеше, сораулары, язуда билгеләү. | 1 | 05.04 | | |
| 84 | Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. Җөлә кисәкләрен билгеләү тәртибе, аларның аталышы, сораулар кую. | 1 | 10.04 | | |
| 85. | Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. Җыйнак һәм җәенке җөмлә төшенчәсен аңлату; чагыштыру, аеру, куллану. | 1 | 11.04 | | |
| 86. | “Җөмлә” темасы буенча иректле диктант | 1 | 12.04 | | |
| 87. | Хаталар өстендә эш. “Җөмлә” темасы буенча үткәннәрне ныгыту. Тест биремнәре. | 1 | 17.04 | | |
| 88. | Сүзтезмә. Сүзтезмәләрне аера белү, сораулар кую.Сүзтезмәдә сүзләр бәйләнеше, аның ияртүче һәм ияручe сүзләрен аеру. | 1 | 18.04 | | |
| 89 | **Бәйләнешле сөйләм (10 сәгать)**<br>Текст. Бәйләнешле сөйләм. Әйтмә һәм язма сөйләм. | 1 | 19.04 | | |
| 90. | Текст. Тема. Текстның темасын һәм төп фикерен билгеләү, мәгънәле кисәкләргә, өлешләргә бүлү, текстка исем кую. | 1 | 24.04 | | |
| 91. | План. Текстның өлешләре. Текстның планын төзү, сюжетлы картинага таянып, хикәяләр төзү. | 1 | 25.04 | | |
| 92 | Сөйләм этикасы белән танышу, план төзү; язма сөйләм нормаларын, язылыш кагыйдәләрен искә төшерү. | 1 | 26.04 | | |
| 93 | Сөйләм этикасы белән танышу, план төзү; язма сөйләм нормаларын, язылыш кагыйдәләрен искә төшерү. | 1 | 01.05 | | |
| 94 | Эндәш сүзләр белән танышу. | 1 | 02.05 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 95 | Тасвирлау һәм хикәяләү текстлары. | 1 | 03.05 | | |
| 96 | Автобиография язу үзенчәлеге белән танышу | 1 | 08.05 | | |
| 97. | **Контроль күчереп язу. №4.** | 1 | 10.05 | | |
| 98. | Хаталар өстендә эш. “Бәйләнешле сөйләм” темасы буенча үткәннәрне ныгыту. Тест биреме. | 1 | 15.05 | | |
| 99. | **Ел буена үткәннәрне кабатлау (4 сәгать)**<br>“Сүзнең төп (лексик) мәгънәсе” темасы. | 1 | 16.05 | | |
| 100. | **Исем.**<br>**Грамматик биремле контроль диктант. №5. 4 нче чирекне йомгаклау.** | 1 | 17.05 | | |
| 101. | Хаталар өстендә эш.Сүз төзелеше. Сүз ясалышы. | 1 | 22.05 | | |
| 102. | Йомгаклау. | 1 | 23.05 | | |

**IX .Укыту-методик әсбаплар белән тәэмин ителеш:**

1. Татар теле – татар башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 3 нче сыйныфы өчен дәреслек 1 кисәк ,И.Х.Мияссарова,
К.Ф. Фәйзрахманова. Казан, “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты, 2020.

2. Татар теле – татар башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 3 нче сыйныфы өчен дәреслек 2 кисәк ,И.Х.Мияссарова,
К.Ф. Фәйзрахманова. Казан, “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты, 2020.

3.“Татар башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 3 нче сыйныфында эшләүче укытучылар өчен методик кулланма” И.Х.Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова. Казан, “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты, 2015.

4.И.Х.Мияссарова, К.Ф. Фәйзрахманова. Татар теле – “Мөстәкыйль эш дәфтәре”- татар башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 3 нче сыйныфы өчен - Казан, “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты, 2015.

В данной рабочей программе по родному(татарскому) языку

пронумеровано, прошнуровано и скреплено печатью МБОУ "Каракашлинская ООШ"

14(четырнадцать)

страниц

Директор школы: [signature]

М.Ш.Закиров